ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 12 » декабрь 2019 ел** **№ 1094**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Хатын-кызлар советы төзү турында**

Җәмгыятьтә хатын-кызларның мәнфәгатьләрен һәм лаеклы урынын яклау, иҗтимагый-сәяси, икътисадый, мәдәни тормышта аларның ролен күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Хатын-кызлар советы төзергә.

2. Кушымта итеп бирелгән:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Хатын-кызлар советы турында Нигезләмәне;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Хатын-кызлар советы составын расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.И. Гарифҗановка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә. Галимуллин

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
2019 елның 12 декабрь
1091 номерлы карары белән
расланган

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Женский совет төзү турында**
**Нигезләмә**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Хатын-кызлар советы (алга таба- Хатын-кызлар советы) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы граждан җәмгыяте институтларын алга таба үстерү, Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының хатын-кызлар һәм балалар мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру, иҗтимагый-сәяси, икътисадый, социаль һәм мәдәни тормышта хатын-кызларның ролен күтәрү, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенә Хатын-кызлар советы компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр әзерләү өчен коллегиаль киңәшмә орган булып тора.

1.2. Хатын-кызлар советы - ирекле, бәйсез иҗтимагый оешма. Гаилә институтын торгызу, гаилә иминлеге өчен гражданлык җаваплылыгы, хатын-кызлар һәм балаларның хокукларын тану һәм үтәү турында җәмәгатьчелек фикерен үстерү өчен җаваплы.

1.3. Хатын-кызлар советы үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы закон актлары, Арча муниципаль районы Уставы һәм муниципаль хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.4. Хатын-кызлар советы эшчәнлеге хәбәрдарлык һәм ачыклык, этика нормаларын үтәп, фикерләр күптөрлелеге һәм демократия принципларында тормышка ашырыла..

**2. Хатын-кызлар советының бурычлары**

2.1. Хатын-кызлар советының төп бурычлары түбәндәгеләр:

- хатын-кызларның һәм балаларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итүдә катнашу;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенә хатын-кызларның һәм балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозулар турында системалы рәвештә хәбәр итү;
- җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга ярдәм итә торган сәбәпләрне һәм

шартларны ачыклауда катнашу, хокук саклау органнарына мәгълүмат җиткерү;

- халыкның мәдәни дәрәҗәсен күтәрүдә катнашу;

- гаилә институтын ныгыту, ана булу дәрәҗәсен күтәрү;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә Арча муниципаль районы территориясендә аналар һәм балалар проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр эшләү һәм карауга кертү;

- балаларның гармонияле үсешенә, матди һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә, патриотик һәм гуманистик фикерләүгә ярдәм итү;

- гаилә сәясәте, белем алу, мәдәният, сәламәтлек саклау, халыкны социаль партнерлык нигезендә социаль яклау мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итү;

- Россия Федерациясенең милли иминлеге нигезе буларак уңышлы гаиләгә юнәлдерелгән дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының гаилә сәясәтен пропагандалау һәм популярлаштыру;

- аналар һәм балалар мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенә тиешле тәкъдимнәр әзерләү;

-Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тәкъдиме буенча Хатын-кызлар советы компетенциясенә кагылышлы башка мәсьәләләр буенча фикер алышу;

- гаиләнең сәламәтлеге, аналарны һәм балаларны социаль яклау, хатын-кызларның социаль хокуклары мәсьәләләре буенча агарту һәм консультация эшчәнлегенең төрле рәвешләрен оештыру;

- массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлекне оештыру, телевидениедә чыгышлар, күргәзмәләр, лекторийлар, башка мәдәни-агарту чаралары оештыру;

- Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарына гаилә сәясәте өлкәсендәге хәлләр һәм тенденцияләр турында мәгълүмат җиткерү, тәкъдимнәр әзерләү;

- хатын-кызларны социаль әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җәлеп итүгә юнәлдерелгән очрашулар, җыелышлар һәм башка чаралар оештыру һәм уздыру.

2.2. Хатын-кызлар советы шәхси мәсьәләләр буенча, шул исәптән мөлкәти, торак һәм хезмәт бәхәсләре белән бәйле мөрәҗәгатьләрне, шулай ук судларның, тикшерү органнарының карарларына шикаятьләрне карамый.

**3. Хатын-кызлар советының хокуклары**

3.1. Үзенә йөкләнгән бурычларны башкару өчен Хатын-кызлар советы түбәндәгеләргә хокуклы:

- җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, муниципаль предприятиеләрдән һәм учреждениеләрдән, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларыннан Хатын-кызлар советы эшчәнлегенә бәйле мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүмат һәм материаллар соратып алырга;

- үз утырышларына Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары

вазыйфаи затларын, иҗтимагый берләшмәләре вәкилләрен чакырырга;
- җирле үзидарә органнары, Арча муниципаль районының Хатын-кызлар советы компетенциясенә керә торган проблемалар буенча иҗтимагый берләшмәләре уздыра торган киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә.

3.2. Хатын-кызлар советы әгъзалары эшчәнлеге түләүсез нигездә алып барыла.

3.3. Хатын-кызлар советы үз эшчәнлеген әгъзаларының һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең уртак карары буенча туктата.

**4. Хатын-кызлар советының эшен оештыру**

4.1. Хатын-кызлар советы турындагы Нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән раслана.

4.2. Хатын-кызлар советы җитәкчелеген Хатын-кызлар советы рәисе, ә ул югында рәис урынбасары башкара. Хатын-кызлар советы секретаре Хатын-кызлар советы эшен оештыру-техник яктан тәэмин итә.

4.3. Хатын-кызлар советы рәисе, аның урынбасары һәм секретаре Хатын-кызлар советы утырышында турыдан-туры аның составыннан сайланалар.

4.4. Совет рәисе:

- Хатын-кызлар советы эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;
- Хатын-кызлар советы эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгели һәм раслый;
- Хатын-кызлар советы утырышларын уздыру урынын һәм вакытын билгели;
- Хатын-кызлар советы утырышларында рәислек итә.

4.5. Хатын-кызлар советы рәисе урынбасары Хатын-кызлар советы утырышын рәис булмаганда алып бара.

4.6. Хатын-кызлар советы секретаре:

- Хатын-кызлар советы әгъзаларына Хатын-кызлар советы утырышларын уздыру урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, Хатын-кызлар советы утырышларында фикер алышу өчен кирәкле мәгълүматны (күбесенчә электрон рәвештә) җибәрә;
- Хатын-кызлар советы утырышлары материалларын оештыру әзерлеген тәэмин итә;
- беркетмә алып баруны тәэмин итә;
- Хатын-кызлар советы председателе йөкләмәләрен үти.

4.7. Хатын-кызлар советы әгъзалары:

- Хатын-кызлар советы утырышына чыгарылган мәсьәләләрне әзерли һәм алдан карый;
- Хатын-кызлар советының эш планы буенча тәкъдимнәр кертәләр;
- Хатын-кызлар советы утырышында катнашалар.

4.8. Хатын-кызлар советы үз эшчәнлеген әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә бәян ителгән бурычлар һәм Хатын-кызлар советы карары белән раслана торган

еллык эш планы нигезендә гамәлгә ашыра.

4.9. Хатын-кызлар советы утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Кирәк очракта Хатын-кызлар советының чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

4.10. Хатын-кызлар советы утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

4.11. Хатын-кызлар советы әгъзалары Хатын-кызлар советы утырышларында шәхсән катнашалар. Хатын-кызлар советы әгъзаларын аларның вәкилләре алыштыру рөхсәт ителми.

4.12. Хатын-кызлар советы карарлары утырышта катнашучы Хатын-кызлар советы әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Хатын-кызлар советы членнарының барысы да хәлиткеч тавыш хокукына ия. Тавышлар тигез булганда хәлиткеч тавыш хокукына Хатын-кызлар советы рәисе ия, ул булмаганда - Хатын-кызлар советы утырышында рәислек итүче Хатын-кызлар советы рәисе урынбасары.

4.13. Хатын-кызлар советы карарлары рәислек итүче тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

4.14. Хатын-кызлар советы карарлары киңәш характерында. Кабул ителгән карарлар, тәкъдимнәр, тәкъдимнәр турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе игътибарына җиткерелә.

4.15. Хатын-кызлар советы утырышына, кирәк булганда, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, башка кызыксынган оешмалар вәкилләре, экспертлар, белгечләр, галимнәр, башка кызыксынучы затлар чакырыла. Чакырылган затлар карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашырга һәм үз тәкъдимнәрен кертергә хокуклы.

4.16. Хатын-кызлар советы тарафыннан тикшерелә торган мәсьәләләр һәм Хатын-кызлар советы утырышында кабул ителгән карарлар җәмәгатьчелеккә массакүләм мәгълүмат чаралары аша җиткерелергә тиеш.

**5. Йомгаклау нигезләмәләре**

5.1. Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр Хатын-кызлар советы әгъзалары тәкъдиме буенча кертелә һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең аерым карары белән раслана.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
2019 елның 12 декабрь
109 номерлы карары белән
расланган

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы хатын-кызлар советы**
**СОСТАВЫ**

Гатауллина Әлмира Мидхәтовна - рәис

Нурмөхәммәтова Рузия Илсуровна- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында Россия Пенсия фонды идарәсенең Арча районындагы клиент хезмәте җитәкчесе (бүлек хокукында), рәис урынбасары;

Бәхтиярова Фәридә Рәүфовна- Арча муниципаль районы ГХАТ бүлеге җитәкчесе, секретарь

**Комиссиия әгъзалары:**

Фәйзрахманова Лилия Рубисовна - “Арча үзәк район хастаханәсе” баш табибының поликлиника эше буенча урынбасары;

Гапдерахманова Гүзәл Әдһәмовна- Арча район Советының оештыру-гомуми бүлеге җитәкчесе;

Вафина Рәмзия Рамазановна- Урта Курса авыл җирлеге башлыгы

Гарәфиева Лилия Гомәровна- «Металл» ЖЧҖ директоры;

Кавиева Рәмизә Рәисовна- «Ашытбаш УББМ» МБМУ директоры

Зәкиева Гөлсинә Вазыйховна- "Арча хәбәрләре" район газетасы журналисты

Сәмиева Наилә Рәисовна - «Баланы үстерү үзәге - Арча шәһәренең 4 нче балалар бакчасы» МББМУ директоры;

Сабирова Гөлнара Барыевна - Арча балалар сәнгать мәктәбе директоры;

Фатыхова Люция Рәшидовна - 3 нче мәктәп директоры;

Заһидуллина Гөлнара Рафисовна - ТР Арча муниципаль районы «Өмет чаткысы» мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләрне тернәкләндерү үзәге» директоры;

Мөхәммәтшина Алинә Таһировна - "Арча Үзәк китапханәләр системасы" директоры;

Фәтхуллина Рая Ахуновна - пенсионер;

Шәймуллина Фрадия Сәмигулловна - пенсионер.

Кирәк булганда, комиссия утырышына Арча муниципаль районының авыл җирлекләре хатын-кызлар советы рәисләре чакырыла.